КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 8 декабрь г.Казань № 1583

«Сиделка» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Сиделка» хезмәтен күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында

«Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән «Сиделка» хезмәтен күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Сиделка» хезмәтен күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 8 декабрь, 1583 нче
карары белән расланды

## «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карары (алга таба – 77 нче карар) белән расланган «2021 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмә буенча «Сиделка» хезмәте күрсәтү чыгымнарын формалаштыру механизмнары билгеләнә.

1.2. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар законнарда билгеләнгән таләпләр нигезендә «Сиделка» хезмәте күрсәтү өчен кирәкле финанс чаралары күләменнән гыйбарәт.

1.3. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар нигезендә исәпләп чыгарылган финанс акчасы күләменнән гыйбарәт.

1.4. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләү чыгару «Сиделка» хезмәте күрсәтү тарифын раслау өчен чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты проектын формалаштырганда елга бер тапкыр «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

«Сиделка» хезмәте күрсәтү тарифы 77 нче карар белән расланган 2021 – 2024 елларда юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга «Сиделка» хезмәтләре күрсәтелүгә бәйле рәвештә чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен гамәлгә ашыру кысаларында «Сиделка» хезмәте белән тәэмин итүчегә компенсация түләү һәм «Сиделка» хезмәте күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү өчен кулланыла.

1.5. Әлеге Нигезләмәдә 77 нче карар белән расланган 2021 – 2024 елларда өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру кысаларында «Сиделка» хезмәте күрсәтү проектын гамәлгә ашыру тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәнең кушымтасында китерелгән «Сиделка» хезмәте кысаларында күрсәтелә торган социаль хезмәтләрнең тәкъдим ителә торган исемлеге нигезендә «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны һәм «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативларын исәпләү тәртибе билгеләнә.

1.6. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар бер айга бер хезмәт күрсәтелүче исәбеннән билгеләнә.

1.7. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативлары бер сәгать «Сиделка» хезмәте күрсәтү өчен билгеләнә.

## II. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе

2.1. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар түбәндәге формула буенча билгеләнә:($NFZ_{sid}$)

$$NFZ_{sid} = R_{FOT_{sb}} + (R_{FOT_{sb}} \times K_{nr}),$$

монда:

$R_{FOT_{sb}}$ – «Сиделка» хезмәте күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) бәясе;

$K_{nr}$ – өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүче социаль хезмәтләр белән тәэмин итүчеләр өчен 0,08гә тигез кабул ителә торган өстәмә чыгымнар коэффициенты.

2.2. «Сиделка» хезмәте күрсәтүче персонал хезмәтләренең стандарт (база) бәясен ($R_{FOT_{sb}}$) исәпләү түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$R_{FOT_{sb}} = N_{psb} \times O_{sb} + e,$$

монда:

$N_{psb}$ – 1 тигез кабул ителә торган «Сиделка» хезмәте күрсәтүче персоналның штат саны нормативы;

$O_{sb}$ – «Сиделка» хезмәте күрсәтүче персоналның хезмәтенә түләү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 ел, 31 март, 1981 нче карары белән расланган 2023 елда Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнар һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын булдыру буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда өйдә карауга мохтаҗ гражданнарга өйдә социаль хезмәт күрсәтү рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтүче Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларының «карау буенча ярдәмче» һөнәре буенча хезмәткәрләренең хезмәт хакын билгеләү үзенчәлекләре турындагы нигезләмә буенча исәпләп чыгарыла торган чыгымнары;

e – хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләнгән акча чыгымнары.

## III. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативын исәпләү тәртибе

3.1. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы ($PNF_{sid}$) бер сәгатькә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$PNF_{sid} = \frac{NFZ_{sid}}{\frac{H_{rd}}{12}},$$

монда:

$NFZ_{sid}$ – «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнар;

$H_{rd}$ – Татарстан Республикасы территориясендә эшчәнлек алып баручы эш бирүчеләр өчен агымдагы елда җитештерү календаре белән билгеләнгән 40 сәгатьлек эш атнасында агымдагы елда эш вакыты нормасы;

12 – бер елда айлар саны.

## IV. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә финанс белән тәэмин итүне исәпләү тәртибе исәпләү тәртибе

4.1. «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә финанс белән тәэмин итү чыгымнары ($FO_{sid}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FO_{sid} = PNF_{sid} \times P_j,$$

монда:

$PNF_{sid}$ – «Сиделка» хезмәте күрсәтүгә җан башыннан финанслау нормативы;

$P_j$ j-өлкән яшьтәге гражданга (инвалидка) «Сиделка» хезмәте күрсәтү турындагы шартнамә нигезендә күрсәтергә планлаштырыла торган карау сәгатьләре саны.

---